**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлегенең Протопопово авылында гражданнар җыены карары**

13.11.2024 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Мөкерле авыл җирлегенең Протопопово авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Мөкерле авыл җирлегенең Протопопово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Протопопово авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзүгщ, ремонтлауга, карап тотуга (юлларны ремонтлауга) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Мөкерле авыл җирлегенең Протопопово авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Мөкерле авыл җирлеге башлыгы _________ С.Н. Тюплина

Халык җыены секретаре _________ Т.Н. Орлова